# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

*Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№5 Март 2023 ел*

**Бәйрәм белән гүзәл затларыбыз!**




**Елның иң назлы, якты һәм матур көне — 8 Март! Яз башы, табигатьтә тормыш башы, елның беренче җылы көннәре… Бу җылы йортыгызны һәм җаныгызны җылытсын. Табигатьнең матурлыгы рухландырсын, ә яз башы сезнең тормышыгызда бик кирәкле һәм матур үзгәрешләрнең башлануын хәбәр итсен!**

Бәйрәмегез белән, гүзәл затлар,
Бәхет кояшыгыз якты янсын,
Күңелләрдә изге хисләр тулсын
Илләребез һәрчак тыныч булсын!

2023 ел Укытучы Остаз елы дип билгеләнде, бу уңайдан, без бүгенге һәм үткәнге мәктәп тормышы һәм анда укыткан укытучылар, шулай ук ветеран укытучылар турында тәрбия сәгатьләрендә сөйләшәбез, әңгәмәләр үткәрәбез. Укытучыларның эшчәнлеге күпкырлы. Алар аң белем бирүчеләр, киләчәк буынны тәрбияләүчеләр. Аерым тәрбия сәгатьләрендә без яраткан укытучыларыбыз турында да сөйләштек. Укучыларның фикерләре төрле һәм бик кызыклы. “Яраткан укытучым турында” темасына алынган язмалар белән таныштырып китәм.

Хафизов Ислам: Укытучы профессиясе иң борынгы Греция чорыннан килә.Шул вакыттан ук беренче мәктәпләр, уку йортлары барлыкка килгән. Укытучы һөнәре укучыларга белем бирү белән генә чикләнми. Алар укучыларны киләсе тормыш өчен, җәмгыятькә алмаш итеп хәзерлиләр.

Закиров Илхам: Яраткан укытучым Зарипов Булат абый акыллы да шаян да, дәресләрен көтеп алам, миңа физкультура дәресләре бик ошый. Кышкы спорт уеннарында күп катнаштык. Хоккей буенча бәйгеләрдә җиңдек.

Шигапов Гадел: Булат абый белән күп бәйгеләрдә катнашабыз, командадагы бердәмлек турында аңлата. Физик хәзерлеккә зур игътибар бирә.

Бариев Фанил: Укытучым Борханова Римма апага мин бик рәхмәтле. Ул безне күп һөнәрләргә өйрәтте, белемле булыгыз дия иде .

Гатауллина Илүзә: Мин информатика дәресләрен яратам, бу дәрес атнага бер генә керә, бик тиз узып китә, Ленар Талгатович безгә төпле белем бирә.

Багавиева Исламия : Информатика дәресләре күбрәк керсә иде.

Багавиев Адел: Физика укытучысы Хәкимҗанов Хәмит абый безгә темаларны аңлаешлы итеп аңлата, таләпчән булса да, аны барысы хөрмәт итә, бу фән барыбыз өчен дә бик кирәк.

Хуснутдинов Илзат: Зарипов Булат абый ТИН дәресләрен тормыш белән бәйләп аңлата. Ул безне якын итә, без дә аны хөрмәт итәбез.

Калимуллина Гөлия: Без укытучыларыбызның барысын да яратабыз, хөрмәт итәбез. Сания Фаритовна миңа сәхнәдә шигырь сөйләү буенча киңәшләр дә бирә. Без бергә конкурсларда катнашабыз.

Гиниятуллин Ислам: география укытучысы Галиева Рәйсә апай белән ОГЭ эшләре өйрәнә башладык. Ул әйбәт җайлы итеп аңлата.

Ахметшин Илназ: башлангыч сыйныф укытучысы Бурганова Римма апа беренче белемнәрне бирде. Ул гадел һәм сабыр, тыныч һәм ягымлы. Әйткән сүзләрен әле дә хәтерлим, мин аңа бик рәхмәтле.

Ганиева Дилә: минем яраткан укутучыларым Хабибуллина Айсылу апа, Батршина Сания апа, алар безгә төпле белем бирәләр.

Камаева Ләйлә: Сания Фаритовна безне 5 класстан бирле укыта. Рус әдәбияты дәресләрендә төрле геройлар турында өйрәнәбез, фильмнар да карыйбыз. Мин укытучымнан гел үрнәк алам, аның кебек белемле буласым килә.

Башлаган эшләребез дәвамлы булсын. Укучылар һәм укытучылар белән кызыклы очрашулар булып торсын. Остазлардан үрнәк алып яшик. Укытучыларбызга рәхмәтле булыйк.

Сыйныф җитәкчесе : Ганиева Ләйсән Фәргать кызы

**Минем дәү әнием!**



2023 ел - Укытучы Остаз исеме астында уза. Укытучылар, аларның тормыш юлы, мәктәптәге эшчәнлеге турында өйрәнәбез. Мин дәү әнием белән матур истәлекләр һәм фотолар аша гына таныш. Әнием һәм туган-нарым сөйләгәннәрдән ул бик көчле шәхес, абруйлы укытучы булган. Язмам Дәү Әнием турында .

Минем дәү әнием,Зарипова Роза Зәки кызы,1932 нче елның 19 нчы маенда Әтнә районы Шекәтә авылында туа.Әтисе Абдуллин Әхмәтзәки директор, әнисе Абдуллина Гөлсем башлангыч сыйныф укытучысы була. Дәү әнием гаиләдә дүртенче бала булып туган. Бала чагы сугыш елларына туры килә... Абыйлары белән бергәләп кырдан черек бәрәңге җыю да, Ашыт буеннан камыш җыю да, алабута ипиләре ашау да аны читләтеп үтмәгән. Дәү әни мәктәптә бик тырышып укыган.10 нчы сыйныфны бетергәч, Казанга пединститутка укырга керә. Аны уңышлы гына тәмамлагач, Кырлайга укытырга кайта.Төрле авылларда төрле мәктәпләрдә укытырга туры килә аңа. Соңрак дәү әтием белән танышып, гаилә коралар, Куәм авылында яши башлыйлар. Дәү әнием лаеклы ялга чыкканга кадәр Куәм урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты фәнен укыткан. Бик күп балаларга белем һәм тәрбия биргән. Тирән белемле булганы өчен аны “аяклы энциклопедия” дип дә йөрткәннәр,гомергә ул Роза Закиевна булып калган (гадәттә авыл җирлегендәге укытучыларга “апа”дип дәшәләр иде). Авыл халкының олысы да ,кечесе дә аны хөрмәт иткән. Әнием сөйләгәнчә: -Пенсиягә чыкканан соң да “Сложнопод-чинённые предложения”не немец телендә аңлата алган. Ә химия фәненең катлаулы формулаларын ялгышмыйча яза торган булган”. Димәк, аның хәтере бик яхшы булган. Ул күп укыган, күп белгән. Укучыларының хөрмәт иткән укытучысы булган.

Кызганыч, мин дәү әниемне күрми калдым.Ул миңа укуда гына түгел, киңәшләре белән дә ярдәм итәр иде.

Камаева Ләйлә , 8сыйныф

**Мини-футбол.**



10 март көнне башлангыч сыйныф укучылары арасында Шашы мәктәбендә Мини-футбол уен ярышы булды.Ул көнне без зарыгып көттек. Тик нигәдер иртәннән бирле яңгыр коеп яуды. Киез итекләребез белән ничек уйнарбыз дип уйга калдык. Уен иртәдән кичкә кадәр дәвам итте. Без яңгыр дип тормадык 9 команда арасында 5 уенда катнашып җиңүгә дә, җиңелүгә дә ирештек. Рәхәтләнеп карда, суда аунадык. Аяк киемнәре, киемнәребе юеш булса да, без бирешмәдек 4 нче урынны яулап, акчалата бүләккә ирештек. Безнең бер коры җиребез дә юк иде. Әле футбол гына түгел аркан да тартыштык. Үзебезнең көчебезне сынаштык. Ә өйләребезгә кайткач безнең битләребез кызышты, көне буе алган кичерешләр белән уртаклаштык. Фотолар карадык . Шундый күңелле уеннар гел булып торсын иде.

Назмиев Рияз, 4 сыйныф



**Март аенда хөрмәтле укытучыбыз Айсылу Мөбәрәкҗан кызының, оператор Тахир Фоат улының туган көннәре. Аларга зур уңышлар, сәламәтлек, бәхетле тормыш, тынычлык телибез!**

## Татар халкының бәби туе белән бәйле йолалары.

Һәрбер кеше үз халкының үткәнен, бабайларның ничек көн иткәнен, ниләр белән шөгыльләнгәнен, гореф-гадәтләрен, йолаларын белергә тиеш. Чөнки үткәнен белмәгәннең киләчәге юк , ди халкыбыз.

Нәрсә соң ул йола? Йола-теге яки бу халыкның яшәешенә борынгыдан кереп урнашкан тормыш-көнкүреш традицияләрен яки дини кануннарны үтәүгә бәйләнешле тәртип һәм гадәтләр, гореф-гадәтләр.

Халык бәйрәмнәре, йолалары – кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Ул бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра, шулай итеп үзара дуслык, кешелеклелек, бердәмлек сыйфатлары тәрбияләнә. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үсә. Һәр кеше, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, милли тәрбия ала.

Алар арасында елның төрле вакытларына, дини йолаларга, тормыштагы үзгәрешләргә бәйле барлыкка килгәннәре дә шактый. Сабан туе, Яңгыр теләү, Каз өмәсе, Сөмбелә, Карга боткасы, Нәүрүз (язны каршылау), Нардуган (кышны каршы алу) бәйрәмнәре ерак гасырлардан күчә-күчә хәзерге көннәргә килеп җиткәннәр. Аларның кайберләре турында әдәбият дәресләрендә Г.Ибраһимовның "Алмачуар", Г.Бәшировның "Туган ягым – яшел бишек" әсәрләрен укып белсәк, кайберләрен мәдәният учакларында уйнап күрсәтәләр, әле дә халык арасында яшәгәннәре дә бар.

Гаиләгә шатлык, өмет һәм куанычлар өстәп, бала дөньяга килә. Бәби туе башлана. Халкыбызда бәби туу белән бәйле йолалар күп булган һәм хәзер дә саклана. Язмамда шуларга тукталып үтәм.

Иң беренчесе исем кушу. Исем ул кешенең язмышын билгели торган нәрсә дип каралган. Элек-электән мәгънәле эчтәлеккә ия булган исемнәр кушканнар. Мулла килеп азан әйтеп, исем куша, балага бәхет теләп, дога кыла. Исем кушуга хәзер халык бик игътибар итә. Әти-әни баласының бәхетле, озын гомерле, игелекле булуын тели, шуңа күрә сүзлекләрдән карап, укып исем сайлыйлар. Безнең өйдә дә Г.Саттарның "Татар исемнәре" сүзлеге бар. Интернетка кереп тә бик җиңел генә исемнәрнең мәгънәсен белеп була. Соңгы вакытта төрки, гарәп-фарсы исемнәре еш кушыла. Бу халкыбызның дингә, миллилеккә битараф булмавын күрсәтә.

Минем исемем – Зөһрә. Үземнең исемемне бик яратам. Күктә балкып торган йолдыз дигәнне аңлата.

Бәби тугач, икенче бер мөһим эш – ул чәч алу. Кайбер якта бу эшне хатын-кыз башкарган. Аны "Чәч-әни" дип йөрткәннәр. Икенче бер якларда сакал-мыеклы кеше алсын, баланың чәче куе булып чыгар, дип уйласалар, кайбер якта иң карт кеше алсын, дигәннәр. Имеш, бала да аның кебек озын гомерле булыр, дип юраганнар. Ә юраган – юш килә, ди халык.

Тугач, 7 көннән чәч алу - ислам дине буенча да сөннәт гамәл булып тора. Ул баланың баш мие эшчәнлегенә файдалы икән. Атеизм чоч алган совет чорында да бу йоларларны әби-бабаларыбыз саклап кала алган. Беренче чәчне бөти итеп тагу йоласы бүген дә халык арасында яши..Чәчне алгач, үлчәп, көмеш яки алтын бәясе белән исәпләп, авылның иң мохтаҗ кешесенә сәдака илтеп биргәннәр. Бездә әле дә бу гадәт саклана. Минем чәчемне әтием алган. Сәдаканы ялгыз карчык Гөлҗиһан әбигә (хәзер мәрхүм инде, урыны оҗмахта булсын) бирдек, дип сөйли әнием.

Бәби мунчасы... Татар авылларында мунчалар су буенда, йорттан ерак урнашкан булган. Судан ерак торган урамнарда яшәүче хәлсезрәк кешеләрнең мунчасы бөтенләй дә булмаган. 20 гасырның 50-60 елларында авылга 7-8 мунча булып, чираттан ягып кергәннәр.

Бәби мунчасы ягкагда бер чиләк-киянтә су кертү - савап саналган. Чөнки яңа гына бала тудырган анага су китерергә ярамый. Бөтен авыл халкы бу мунчага су китереп, савап ала торган булган. Бәби мунчасына ялгыз карчыкны керткәннәр, атна саен диярлек. Чөнки аның мунчасы юк, ягып керерлек мөмкинлеге дә чамалы. Ялгыз карчыкны мунчага кертү бу гаиләгә бик зур савап. Гел яхшылык эшләп яшәгән борынгылар. Хәзер су краннан гына килә. Шулай да мунчага йөрү гадәте бенең авылда яши әле. Туганнар, күршеләр бер-берсенә мунчага йөриләр.

Бәбине беренче тапкыр мунчада төрле матур сүзләр әйтеп, теләкләр теләп гаиләдәге олы әби, дәү әниләр юа. Баланы тоз суы белән дә коендыралар. Безнең күршебездә яшәүче Миңлегөл апа бәби юу остасы, дияр идем. Мин икенче бала, әниемнең бала юу тәҗрибәсе булгач, үзе юган.

Бала тугач тагын бер гамәл – Гакыйка корбаны чалу. Ир бала туса ике, кыз бала туса берне. Гакыйка корбаны чалу - шулай ук пәйгамбәребездән калган сөннәт гамәл. Яшь парлар бу сөннәтне дә бик теләп башкаралар. Корбан ите туганнарга, күршеләргә, ятимнәргә таратыла.

Безнең халкыбызда матур бер йола – "Бәби чәе" үткәрү сакланып килә. Корьән укыла, балага, гаиләгә бәхет теләп, туганнар дуслар бүләкләр бирәләр.Ә табын түрендә ипи янәшәсендә әлбә тора. Нәрсә соң ул әлбә? Ул бик баллы, тәмле ризык. Хәзер тормышлар бик мул. Нинди генә тәм-том юк. Шулай да бала тугач, әлбә пешерү йоласы бүген дә яши. Авылларда әлбә осталары бар. Без сыйныфыбыз белән мәктәпкүләмендә "Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары. Бәби туе" проектын яклаган идек. Әлеге чарада Илвирның әбисе Суфия апа безне әлбә пешереп сыйладылар. Шулай ук сыйныфташым Айсинәнең әнисе Айсылу апа да әлбәне бик тәмле әзерли.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә, әби-бабайларыбыз югары уку йортлары тәмамламаган, ә гореф-гадәтләр, йолалар, дини белемнәр (фарыз һәм сөннәт гамәлләр) аша тирән белемле, әхлаклы, иманлы, мәдәниятле булып яшәгәннәр. Без, яшь буын, шул кануннарны тәрбиябезгә, яшәешебезгә нигез итеп алып, алга атлыйк. Садриева Зөһрә, 9 сыйныф

## Яз килә

Кышның салкыннарыннан соң мин язны сагынып көтеп алам. Яз табигатьнең кышкы йокыдан уяну вакыты.Аның әле кыштан әллә ни аермасы юк.Салкын бураннар да дулый.Кыш белән яз тартыша. Ә кояш барыбер үзенекен итә, җылыта, күзләрне чагылдыра. Түбәләргә боз соңгеләре дә элеп куя.

Чыпчыклар да күңеллерәк чыркылдаша. Көннәр дә озая бара. Яз кояшы безгә елмаеп карый. Тиздән яз кояшы агачтагы бөреләрне дә уятыр, елгаларда бозларны кузгалтыр. Без сагынып алган язгы каникуллар да башланыр.

Яз –матур, шатлыкларга бай, күңелле вакыт.

Мирхазианова Алия 4 класс

## Күңелле очрашу



15 нче мартта, Күәм урта гомуми белем мәктәбендә бик кызыклы очрашу булып узды. Безгә кунакка экологлар Абдрахманова Гөлнара Ильяс кызы белән Шаймуллина Алия Ринат кызы килде. Алар "Чүп-чарны аерып җыя беләбезме?" темасына тәрбия сәгате үткәрделәр.

Кунаклар безгә экология фәне турында, Җиребез – туган йортыбызның чисталыгы кешеләрнең үзләреннән торуы, чүп-чарның урман-болыннарда, елга-күлләрдә җыелып ятуыннан бик күп хайваннарның зыян күрүе, табигатьтәге башка экологик проблемаларны бик тәфсилләп аңлаттылар. Безнең белән төрле тәҗрибәләр үткәрделәр, уеннар уйнадылар. Без чүпләрне төрле контейнерларга бүлеп тутырдык. Иске кәгазьләрне аерып җыеп, 1 тонна макулатура тапшырсак, 10 агачны саклап калганны белдек. Алга таба да, макулатурага тапшырырга кирәк дигән фикергә килдек. Шулай ук батарейка, аккумуляторларның җиргә бик күп зыян салуы, туфракны агулавы турында да аңгәмә узды.

Кунакларыбыз буш кул белән килмәгән. Алар төрле экологик конкурсларда катнашкан өчен дипломнар, бүләкләр, тәнәфесләрдә уйнар өчен төрле уеннар да алып килгәннәр. Без аларны киләсе елга да көтеп калабыз.

Низомов Джамшит, 2 сыйныф

**Яңалыклар**

- Балалар язучысы Дәрҗия Сәйфулла кызы Аппаковaның тууына 125 ел (1898–1948) )
- **Якташыбыз актёр, режиссёр, ТАССРның халык артисты Хәким Йосыф улы Сәлимҗановның тууына 120 ел (1903–1981)**
- Шагыйрь, прозаик, драматург Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзинең (Фәйзуллинның) тууына 120 ел (1903–1958)
- Рәссам Илгиз Хановка 75 яшь (1948)
- Рус педагогы, язучы К.Д.Ушинский тууына 200 ел(1823-1870)
- 27 март - Бөтендөнья театр көне.
- 2014 елның 18 мартында Крым Россия составына кушылды.